КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 11 ноябрь г.Казань № 983

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Украина территориясендә, Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә даими яшәгән, торак урыннарны мәҗбүри ташлап киткән һәм Татарстан Республикасы территориясендә вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларында булган Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затларны урнаштыру һәм аларның туклану чыгымнарын каплау турында» 2022 ел, 30 апрель, 406 нчы карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Украина территориясендә, Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә даими яшәгән, торак урыннарны мәҗбүри ташлап киткән һәм Татарстан Республикасы территориясендә вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларында булган Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затларны урнаштыру һәм аларның туклану чыгымнарын каплау турында» 2022 ел, 30 апрель, 406 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 22 август, 883 нче; 2023 ел, 21 гыйнвар, 30 нчы; 2023 ел, 12 август, 973 нче; 2024 ел, 6 май, 304 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 2 пункттагы «чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә (каплауга)» сүзләрен «чыгымнарын каплауга» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Бу карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин